СОВЕТ СРЕДНЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРТА ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Урта Тигәнәле **КАРАР**

23.05.2023 № 36

Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, йә варисларның берсенең дә мирас итеп алырга хокукы булмаса яисә барлык варислары варислардан читләштерелгән булса, йә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, йә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса;

2) салым түләүче гражданның-физик затның стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән өч еллык срокның тәмамлануы;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.

2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советының 04.07.2017ел, № 46 «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча недоимка һәм бурычларны түләтүгә һәм юкка чыгаруга ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен раслау турында» карары.

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советының 04.07.2017ел, №47 «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча недоимка һәм пенялар буенча бурыч түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибе турында» карары.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Родники авыл җирлегенең мәглүмати стендында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Урта Тигәнәле авыл җирлеге**
**Башлыгы, Совет Рәисе** **И.К.Хәмәтвәлиев**